ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АГРАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 15 09.06.2020 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, муниципаль Аграмак авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Аграмак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны турында квартал саен белешмәләрне һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны бастырып чыгару тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р. Т. Галәветдинова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АГРАМАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1637005496

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак
авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
2020 елның 9 июненнән № 15

## Аграмак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Аграмак авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен бирелә торган белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе (алга таба - Тәртип) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Аграмак авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Тәртип Аграмак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә фактик чыгымнар турында квартал саен бирелә торган мәгълүматларны (алга таба - белешмәләр) тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели.

### II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру һәм аларның составы

2.1. Белешмәләр квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача исемлек саны турында, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Аграмак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына карата түләүләрне исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын гамәлгә ашыруга фактта җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен (акчалата тотуны) чагылдыра.

2.2. Белешмәләр хисап чорыннан соң килә торган айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге рәвеш буенча тапшырыла.

2.3 Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

### III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе

3.1. Аграмак авыл җирлегенең башкарма комитеты хисап чорыннан соң килүче айның соңгы санынннан да соңга калмыйча Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетының белешмәләрне раслау турындагы карары проектын әзерли.

3.2 Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр хисаптан соң килүче икенче айның соңгы санына кадәр Аграмак авыл җирлеге сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен бирелә торган белешмәләрне бастырып чыгару тәртибенә кушымта

Аграмак авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең саны һәм аларның хезмәте өчен хисап чорының ________20___елгы түләүгә факттагы чыгымнар турындагы белешмәләр (беренче квартал, яртыеллык, тугыз ай, бер ел)

| Хезмәткәрләр категориясе | Хисап чорында хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны, кеше | Хисап чорында хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |